СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*25 ноябрь, 1998 ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 134 (8291)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# АВЫЛ ЯЗМЫШЫ - АВЫЛНЫҢ ҮЗ КУЛЫНДА

## *(Район семинар - киңәшмәсеннән)*

Иске - яңаны саклый, дисәләр дә, сүз авыл хуҗалыгы техникасы турында барганда, хәзерге акча кытлыгы заманында машина - тракторларның да, комбайннар һәм тагылма эш коралларының да яңасын алу хакында авыз ачарга да юк. Сүз бары тик булган техниканы саклабрак тоту, ватылганын вакытында төзәтү, мөмкин булганча сафка бастыру, яңарту турында гына барырга мөмкин. Шимбә көнне хуҗалык рәисләре, хакимият аппараты, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең баш белгечләре катнашында узган семинар - киңәшмәне йомгаклагандагы чыгышында хакимият башлыгы **Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН** төп басымны нәкъ менә шушы мәсьәләгә ясады да. Район җитәкчесенең хуҗалыклардагы техника паркы язмышы өчен чын - чынлап борчылуы юкка түгел, чөнки, бердән, илдәге кризис аркасында күп кенә авыл хуҗалыгы машиналары җитештерелми, икенчеләре - якын чит илләрдәге заводларда эшләнә, икенчедән, матди һәм финанс кытлыгы аркасында, техниканың булганын язгы чәчү, терлек азыгы әзерләү һәм урып -җыю чорына әзерләүнең никадәр авырга килүен чамалавы да кыен түгел. Шуны ачык аңлаган хуҗалыкларда бу эштә ныклы тәртип булдырып, аны эзлекле төстә алып барып кына азмы - күпме тынычландырырдай нәтиҗәгә ирешергә мөмкин булуын истән чыгармыйлар. Ул җәһәттән семинарда катнашучыларны техникага караш та игътибарга лаек булган, аны кышкы саклауга кую һәм ремонт эше дә җиренә җиткереп оештырылган урынга - "Кондырча" хуҗалыгының Югары Нурлат кооперативына алып барулары юкка түгел иде. Биредә техникага чын хуҗаларча карауларына кунакларның күбесенең исләре китте. Дөрес, мондый үрнәк тәртип бер биредә генә дигән сүз түгел, шулай да күпчелек җитәкчеләр мондагыны үз хуҗалыкларындагы белән шактый көнләшеп чагыштырып карадылар. Ә чынлыкта көнләшергә урын юк, чөнки кондырчалыларга да беркем читтән килеп эшләп бирми. Әле, киресенчә, үзләренең техникалары ышанычлы булгач, алар теге яки бу кыр эшләрен бары тик үз көчләре белән генә башкарып чыгарга тырышалар һәм шуңа ирешәләр дә. Гаражлардагы, мастерскойлардагы тәртип тә өстән кушканга гына эшләнгән нәрсә түгел. Бу хуҗалыкта техниканы саклауга кую, ремонтлау, техник карау үткәрүнең ничек оештырылуы турында җентекләп сөйләгән "Гостехнадзор" инспекциясе начальнигы Р.С.Сатдаров аерым билгеләп үткәнчә, биредә техника турында теге яки бу мөһим эш чоры килеп җиткәч кенә түгел, ә ел әйләнәсе истә тоталар. Моның шулай икәнлегенә кунаклар үзләре дә инандылар. Катлаулы техника, тагылма кораллар эшләр төгәлләнү белән тиешенчә саклауга куелган монда. Кышкы чорда кулланылмый торган тарту көчләре дә бер урынга тупланган. Ә ремонт таләп ителә торганнарын менә дигән эш шартлары булган мастерскойда төзәтеп яталар. Көз буяр өчен берәр тырма яки культиватор гына кертмәгәннәр, ә бөртекле ашлык комбайннары да, терлек азыгы әзерләү техникасы да әнә көзеннән үткәрелә монда. Ә бит соңгысына күп хуҗалыкларда печәнгә төшәргә атна - ун көн калгач кына, эшче кулларның һәрберсе исәптә чакта гына тотыналар һәм күп нәрсәне кулдан ычкындыралар. Башкасын әйткән дә юк, быел иң соңга калган эш - шикәр чөгендере казуда кирәге чыга торган БМнарны да ремонтлап бетереп киләләр инде Югары Нурлатта. Ә ремонт эшенә чыннан да җитди караш булуына моннан да саллырак нинди мисал китерергә мөмкин ди тагын. Гамәлдәге техника тотыла торган гараждагы тәртип тә механизатор һәм шоферларның үзләреннән тора. Техник хезмәт күрсәтү пунктында да игътибарга алырлык нәрсәләр күп. Ә эшләүчеләрнең үз хезмәтләренә шулай җаваплы каравы аларга тиешле шартлар да тудырып, ныклы таләпчәнлек тә күрсәтелүдән килә. Гаражлар һәм мастерскойда җылы, соңгысында менә дигән көнкүреш бүлмәсе җиһазланган, сиксәненче еллар уртасында оештырылган сәламәтлек комплексын да таркатмаганнар биредә, киресенчә, кайбер түрәләрнең кабинетларына биргесез иттереп җиһазлап тәртиптә тоталар. Ә инде ремонтланган бер авыл хуҗалыгы техникасын махсус комиссия кабул итеп ала, түләү дә шул комиссия үз сүзен әйткәч кенә үткәрелә.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

## Уңган кеше һәр җирдә кадерле




***Марат - яшьтән хуҗалык маллары арасында эшләп үскән егет. Әтисе Галимулла Гамирулла улы фермада терлекче, ә әнисе Сания Касыймовна сыер савучы булып озак еллар эшләделәр колхозда. Марат әтисенә ярдәмгә дә, әнисенә булышырга да фермага еш килә иде. Өлкәннәр үсмер Маратның кулы эшкә ятып торуын шул чакта ук күреп өлгергән иделәр инде, "Менә үзең дә терлекче булырсың әле", - дип еш кабатлыйлар иде. Юраганнары юш килде: Марат 6 ел инде әти - әнисе һөнәрен дәвам итә. Яшьтән алган күнекмәләре бик ярап куйды: эшкә тиз күнде, әти - әнисе төсле хөрмәтне дә тиз яулады. Хезмәткә тугрылыкта да шулай ук әти - әниләренә охшаса иде, дип телиләр "Чулпан"да. Чөнки уңган кеше һәр җирдә кадерле.***

***Рәсемдә: "Чулпан" КХАсы терлекчесе М.Г.Шәрәфетдинов.***

### «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

Халыкара инвалидлар көне җитә

*"Алтын йөрәк" акциясе*

## БЕР - БЕРЕБЕЗГӘ БУЛЫШЫЙК!

1 - 10 декабрьләрдә шәһәрдә һәм районда Халыкара инвалидлар көне уңаеннан инвалидларункөнлеге игълан ителә. Бу катлам вәкилләре бүген игътибарга, кайгыртуга, шәфкатьлелеккә, матди ярдәмгә аеруча мохтаҗ. Шушы уңайдан инвалидларга ярдәм йөзеннән акча күчерү өчен ачылган җирле исәп - хисап счетының номерын җиткерәбез:

40205810300000170031
БИК 049241000 ИНН
1632002325

Кыен чакта бер - беребезгә булышырга кирәк шул, һәм предприятиеләр җитәкчеләреннән, хезмәт коллективларыннан, эшмәкәрләрдән, аерым кешеләрдән бу счетка кергән иганә акчалары теге яки бу гаиләнең, авыру балалы ананың, ялгыз карт инвалидның проблемаларын хәл итәргә булышачак. Алар безнең ярдәмгә өметләнәләр!

*Рәсми хроника*

## *Рәис алышынды*

"Чулпан" крестьян хуҗалыклары ассоциациясе әгъзаларының 23нче ноябрьдә узган җыелышында оештыру мәсьәләсе каралды. Җыелыш шәхси гаризасы нигезендә хуҗалык рәисе Әнвәр Мингәрәй улы Шәяхмәтовны вазифаларыннан азат итте. "Чулпан" КХАсы рәисе итеп моңарчы "Комбайн" КХАсы рәисе булып эшләүче **Дамир Вакыйф улы ФАССАХОВ** сайланды.

*Хәбәрчебез яза*

## АРМИЯГӘ КИТӘ ЕГЕТЛӘР

Әйе, менә тагын егетләрне армия сафларына озату башланды. Бу алар өчен моңсурак булса да, ил алдындагы изге бурычны намус белән үтәү зарур. Әнә алар, булачак солдатлар: Рөстәм Дәүләтшин, Руслан Исмәгыйлев, Айрат Галиуллин, Рөстәм Абдрахманов һәм Илнур Миндубаев. Егетләргә әйтәсе сүз шул: исән - сау хезмәт срокларын тутырып, туган авылларына әйләнеп кайтсыннар, биргән антларына тугрылыклы булсыннар, әти - әниләре, дуслары белән элемтәне өзмәсеннәр! Изге юл сезгә, егетләр!

## *ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘ ЯҢА СИСТЕМА*

Хуҗалыкта инде бер ай буе яңа - сыерларны бәйләүсез асрау ысулы буенча эшли башладылар. Болай эшләү савучылар өчен күпкә җиңелрәк. Биредә аерым группалар юк. Саву залына һәр ике якка 8әр сыер керә. Һәр сыер алдына улак куелган. Анда фураж салына. Ә сөт турыдан - туры суыткычка китә. Сөтнең майлылыгы да югары - 4,5 процентка җитә. Савучылар сөт ташу, бидон юу мәшәкатеннән азат. Савым беткәч, саву аппаратлары шунда ук кайнар су суыртып эшләү тәртибендә юыла. Бу эшне оператор Азат Гафиятуллин башкара. Терлекләрне саву залына кертеп торуда хисапчы - лаборант Минегаяз Шаһивәлиевның да хезмәте зур. Савым 2 сәгать ярымга сузыла. Ферма мөдире Фәрит Галиуллин, ветеринария врачы Равил Яруллин, зоотехник Вәгыйзь Шәкүров, ясалма орлыкландыру технигы Фәрит Мостафин һәм терлекчелек буенча механик Гомәр Хәйдәровлар һәрчак савучылар янында булалар, үзләренең төпле киңәшләрен бирәләр.

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**"Татарстан" КХАсы савучысы.**

*Белеп торыгыз!*

## ҺАВА ЛИНИЯСЕ АЧЫЛДЫ

Район пассажирларына сөенечле хәбәр җиткерәбез: Казан белән Нурлат арасында тагын һава элемтәсе ачылды. Самолет һәр көнне Казаннан 8.40 сәгатьтә күтәрелә һәм Нурлат аэропортына 9.20 сәгатьтә төшә. Казанга - 9.30 сәгатьтә кузгала, билет бәясе 80 сум.

Кышкы юлларны җиңеләйтергә теләгән юлчыларга бу хәбәр шатлыклы булыр, дип уйлыйбыз. Өстәмә мәгълүматларны 5-43-56 телефоны буенча аэропорт администрациясеннән алырга мөмкин.

## "ЫШАНЫЧ ТЕЛЕФОНЫ"

25 ноябрьдән Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлегендә теге яки бу сәбәп аркасында кем икәнлекләрен белгертергә теләмәүчеләрдән хәбәрләр алу өчен "ышаныч телефоны" эшли башлый. Бер үк вакытта милициянең эшендә нәтиҗәлелекне күтәрү буенча тәкъдимнәр дә көтәбез.

"Ышаныч телефоны" аша алынган мәгълүматлар җинаятьләрне ачу һәм тикшерү, милиция эшендәге җитешсезлекләр һәм негатив фактларны ачыклауда кулланылачак.

*"Ышаныч телефоны"ның номеры 2-12-30.*

Әлегә ул иртәнге 9дан 11гә кадәр һәм көндезге 3тән 5кә кадәр эшли. Алга таба аның тәүлек буе эшләве дә күздә тотыла, ул хакта аерым хәбәр ителәчәк.

Абонентның кемлеген сер итеп саклау гарантияләнә!

***Эчке эшләр бүлеге штабы.***

# АВЫЛ ЯЗМЫШЫ - АВЫЛНЫҢ ҮЗ КУЛЫНДА

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

Инде мәсьәләнең икенче ягына күчик. Техника ремонтлау өчен әнә шундый шартлар була торып та, кондырчалылар әле үзләренең генә хәлләреннән килмәслек эшләрне "Сельхозтехника" район оешмасына тапшыралар икән. Һәм монысы һич тә гаеп эш түгел, киресенчә, - мәсьәләгә чын хуҗаларча, комплекслы карау мисалы. Хуҗалыкның ике Т - 70 тракторы нәкъ берләшмәдә ремонтланып ята хәзерге вакытта. Ә бит күп кенә хуҗалыкларда ул тракторларны, башка төр техниканы ни үзләрендә ремонтламыйлар, ни, мең төрле сәбәп табып булса да, "Сельхозтехника"га да китермиләр. Шуңа семинарның маршруты нәкъ менә шул берләшмәдә төгәлләнүе очраклы түгел иде.

Соңгы елларда колхоз - совхозлар алдында яманаты чыккан берләшмәдә бүген эш оештырылуы ягыннан да, тәртип мәсьәләсендә дә хәл танымаслык булып үзгәргән. Яңа җитәкчелекнең эшкә җиң сызганып алынуы, район һәм "Татсельхозтехника" холдинг компаниясе тарафыннан саллы ярдәм күрсәтелүе нәтиҗәсе дип карарга кирәк моны. Һәм берләшмәнең баш инженеры А.Н. Кузнецов хуҗалык җитәкчеләренә берләшмәдә нинди ремонт эшләре башкарылуы яки башкарырга мөмкин булуы, нинди деталь һәм узелларны яңадан торгыза алулары, кайбер төр авыл хуҗалыгы машиналарын үзләрендә ясаулары һәм ясарга җыенулары турында бик җентекләп сөйләде. Инде традицион ремонт эшләреннән тыш, биредә хәзер катлаулы һәм гаять кыйммәт тора торган "ДОН" комбайннарының барабан асты, аскы һәм өске иләк, вариатор, элеватор чылбыры, тоташтыру муфтасы, тизлек тартмасы кебек мөһим узелларын, терсәкле валларны, чылбырлы тракторларның төп өч узелын һәм башка күп кенә детальләрне сафка бастыра алалар. Аларның барысына да тәфсилләп тукталып тормыйбыз, чөнки техника өчен турыдан - туры җаваплы кешеләр - хуҗалыкларның баш инженерлары да моны үз күзләре белән күрделәр - якшәмбе көнне алар өчен махсус семинар оештырылды. Бары тик механизаторларның кайсы техниканы биредә сафка бастырырга мөмкин булуын белеп торулары гына мөһим. Хакимият башлыгы да семинар - киңәшмәне йомгаклаганда ясаган чыгышында мондый районкүләм чараларда күрсәтелгән яңалыкларның урыннарда һәр эшләүчегә җиткерелүе, әйтелгән сүзләрнең һәркемгә үтемле иттереп төшендерелүе мөһим булуына басым ясады.

Билгеле, барлык техниканы да бирегә генә китереп ремонтлатырга дигән бурыч куелмый, азрак чыгым белән урында башкарырга мөмкин булган эшләрне җирле шартларда башкару мәслихәт, әмма кайбер хуҗалыкларда, алда әйткәнебезчә, үзләрендә я тиешле шартлар, я кирәкле запас частьлар булмауга, я эшне рәтләп оештыра алмауларына да карамастан, "Сельхозтехника"га да мөрәҗәгать итмәүләре нык борчый әле. Шуңа да ремонт эшен бик ашыктырыр бу вакытта тиз арада барлык техникага дефектлау үткәреп, кайсын кайда төзәтү мәсьәләсен хәл кылу, үзләренең генә хәлләреннән килерлек булмаганнарын ашыгыч төстә берләшмәгә китерү мөһим. Ә биредә, әйткәнебезчә, шартлар һәм мөмкинлекләр бар, әлегә, кызганычка каршы, эш фронты гына бик аз. Тагын шунысы да бар, техникасын алданрак китергәннәр аның ашыкмыйча, җиренә җиткереп төзәтеләсенә дә өметләнә алалар бит әле. Дөрес, ул җәһәттән берләшмә быел үзендә ремонтланган һәр нәрсәгә сыйфат гарантиясе биреп чыгарырга ниятли, димәк, моннан ары теге яки бу двигательнең Нурлаттан кайтуга өч көндә шакылдап чыгуы турындагы сүзләр дә азаер, андый очракларда бәхәсне хәл кылуның ныклы механизмы да булыр дип ышанырга мөмкин. Ә ремонтны моннан да ары сузарга вакыт калмады, хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев семинар - киңәшмәнең башында ук билгеләп үткәнчә, күп кенә хуҗалыкларда бу эштә болай да соңга калдылар инде һәм ел ахырына кадәр удар төстә эшләп алмыйча булмаячак.

Тормыш ничек кенә авыр булмасын, безгә берәү дә бернәрсәне дә кулга китереп тоттырмаячак, безнең җирдә бүтән кеше килеп эшләмәячәк тә - үз көнебезне үзебез күрәсе. Шуңа да Ф.С. Сибагатуллин киңәшмәдә ясаган чыгышында илдәге кризисның район икътисадында да нык чагылуын, һәм бу авыр хәлдә бары тик ныклап торып, баръяклы уйлап эшләп кенә яшәп калырга мөмкин икәнлеген кабат - кабат ассызыклады. Моны җитәкчеләр генә түгел, ә һәр эшләүче ачык аңларга тиеш. Шулай да җитәкчеләргә бу мәсьәләдә икеләтә җаваплылык йөкләнә. Авыл хуҗалыгында азмы - күпме тотрыклылыкка ирешик дисәк, бүген иң элек терлекчелекне, аерым алганда малларның баш санын саклап калу мөһим. Итне никадәр күбрәк җитештерсәк, күп мәсьәләләрне хәл итү , шул исәптән хуҗалыкларның бурычы болай да бик күп булган "Сельхозтехника" берләшмәсе белән исәп - хисап ясау да шулкадәр җиңелрәк булачак. Ә инде сөтне дәүләткә никадәр күбрәк сатабыз икән, анысы хуҗалыклар кассасына ике - өч көн саен күпмедер тере акча кереп тора дигән сүз. Соңгысы республика хөкүмәтенең дә аерым контролендә хәзер, һәм хакимият башлыгының сөт җитештерү һәм хәзерләүне былтыргы дәрәҗәдән шактый киметкән хуҗалык җитәкчеләреннән мәсьәләгә ачыклык кертүләрен һәм хәлне төзәтү өчен нинди чаралар күрергә ниятләүләре турында аерым - аерым сораштыруы урынлы иде. Фатих Сәүбәнович, концентрат азык белән билгеле бер ярдәм күрсәтеләсен әйтсә дә, бер үк вакытта малларның баш санын арттыруда, терлекчелек продукциясе җитештерүдә шәхси ярдәмче хуҗалыкларның мөмкинлекләрен дә киңрәк файдаланырга кирәклегенә аерым басым ясады. Шәхси хуҗалыкларда продукция җитештерүне артык чыгымнарсыз һәм нәтиҗәлерәк алып бару һәм барырга мөмкин булуы турында хакимият башлыгы баштан ук тәкърарлап килә инде. Һәм бу мәсьәлә хакында матбугат битләрендә дә аерым җитди сүз алып барырга кирәк булачак әле. Хакимият башлыгы район халкын бәрәңге, яшелчә, кайбер башка продуктлар белән тәэмин итүне җайга салу буенча программ бурычларга да тукталды, ул җәһәттән авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көне уңаеннан котлавында әйткән фикерләрен тагын бер тапкыр кабатлады. Бу уңайдан мәктәп яңы тәҗрибә участокларын киңәйтеп, укучыларны авыл хуҗалыгы культураларын үстерүгә ничек тә күбрәк тарту мөмкинлеге турында мәктәп җитәкчеләре һәм укытучыларның газета битләрендә фикер һәм тәҗрибә уртаклашулары урынлы булыр иде дип уйлыйбыз. Әйтик, Нурлатның дүртенче мәктәбе киләсе елга бәрәңге һәм яшелчә үстерү өчен 3,5 гектар җирне арендага алу турында "Дуслык" хуҗалыгы белән килешү төзегән дә инде. Бу башлангычка башка мәктәпләр дә актив кушылырлар дип уйлыйбыз. Бер үк вакытта хуҗалык җитәкчеләре дә мәктәп коллективларының инициативасын хупларга тиешләр, чөнки, укучылар бәрәңгене никадәр күбрәк үстерсәләр, аның мәктәпнең үз ихтыяҗларыннан калганын хуҗалыкка, беренче чиратта дуңгыз фермаларына ярты кышка җитәрлек итеп әзерләп куярга мөмкин булачак бит.

Кыскасы, семинар - киңәшмәдә күтәрелгән мәсьәләләр, әйтелгән фикерләр бик мөһим һәм җитди иде. Инде шуларны гамәлгә ашыру юнәлешендә нәтиҗәле эшләү бурыч булып тора. Шул очракта гына башкару дисциплинасын ныгыту зарурлыгы турында киңәшмә саен диярлек сөйләргә туры килмәячәк. Һаман саен бер үк мәсьәләләрдә тәнкыйть сүзе ишетү кайбер җитәкчеләрнең үзләренә дә күңелле түгелдер бит инде, югыйсә.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

## АШ ИСЕ, ИКМӘК ИСЕ



***Ипи пешерелә башлагач, "Үрнәк" КХАсының Биляр Озеро ашханәсенә аерата хуш исле, тәмле ис тарала торган булып китте. Икмәк, камыр шундый бар җанны әретерлек хуш ис бирә. Эш шунда: үрнәклеләр шушы көннәрдә генә икмәк пешерү өчен электр миче сатып алдылар да, аны ашханә бинасына урнаштырып, кечкенә пекарня ачып җибәрделәр. Яшь икмәк пешерүчеләр Т.В. Ворсина һәм Н.В.Лялюкова (рәсемдә) әле ипи пешерү, мичтән дөрес файдалану серләрен үзләштереп кенә киләләр. Берьюлы 30 данә икмәк пешерүгә көйләнгән мичтә үрнәклеләр хуҗалыкның эчке ихтыяҗлары- ашханә, мәктәп, балалар бакчалары өчен икмәк пешерергә ниятлиләр. Кем белә, бәлки тора - бара халыкка сатарлык та пешерергә өйрәнеп - остарып җитәрләр. Ни генә булмасын, үз икмәгең булу беркемгә һәм беркайчан зыян итмәс, "Үрнәк" КХАсы идарәсе шулай уйлап ачкан пекарня да уңышлы эшләр дип өметләнәбез.***

***Н.АЗИЗОВ фотосы.***

## Кем ул кем?

Сүзне Русия Федерациясе Президентыннан башлыйк. Борис **Ельцинның әнисе** кыз чагында Старыгина булган. Аңа Клавдия Васильевна дип олылап эндәшкәннәр. Ә Ельцинның хатыны Наина Иосифовна элек Анастасия, Настя Гирина булып йөргән. Бу фамилияләрнең килеп чыгышын профессор Котляровский болай аңлата:

- Старыгина дигән борынгы фамилия "Старый" (карт) дигән сүздән алынган, зирәк, акыллы мәгънәсен аңлата. Димәк, Старыгиннар XVI - XVII гасырларда община башлыклары яки акыллы киңәшчеләр булганнар. Гирина исә татарга бәйле, татар - монголлар Русияне буйсындырып тоткан чордан килә икән. Хәер, Наина Ельцина һәм Татьяна Дьяченконың йөзендә татар чалымнары бар, бигрәк тә алар күз уемнарында чагыла.

Моннан тыш, татарларда башка милләт кешеләре белән никахлашу кебек традиция дә шактый көчле. Хәтерлисездер, Ельцинның беренче кияве дә саф татар бит - Вилен Хәйруллин.

**Анатолий Борисович Чубайс**ның әнисе - Раиса Хаимовна Сагал. Инглизчә бу фамилия SIQAL дип языла, ул Голливуд йолдызы һәм айкидо чемпионы Стивен Сигал фамилиясе белән бер үк. Димәк, Анатолий Чубайсның, Русиядә беренче хосусыйлаштыручы гына булмыйча, Стивен Сигалның кардәше дә булуы ихтимал.

Зур сәясәтнең тагын бер эшлеклесе, элекке Премьер - министр **Сергей Кириенко** егет булып җиткәнче Израитель фамилиясен йөрткән. Бу фамилия аңа әтисе Владилен Израительдән килә. Ә инде әтисе гаиләсен калдырып яшь лаборант янына киткәч, Сереҗаның әнисе булачак сәясәтчегә үзенең кыз чагындагы фамилиясен биргән.

Дәүләт Думасының бик актив депутаты, "юрист улы" **Владимир Жириновский** яшь чагында Эдельман булып йөргән. Бары тик институтка укырга кергәндә генә үги әтисенең фамилиясен алып, Жириновскийга әйләнгән.

Килеп чыгышларына тукталып тормый гына тагын берничә сәяси эшлекленең әнисе ягыннан фамилияләренә тукталыйк. Шулардан берсе - РФның хәзерге Премьер - министры **Евгений Примаков.** Аның әнисе - Киршинблатт, Мәскәү мэры Юрий Лужковның әнисенеке- Сыропятова, Дәүләт Думасы депутаты һәм халык артисты Иосиф Кобзонның әнисенеке - Шойхер, элекке вице - премьер Борис Немцовның әнисенеке - Эйдман, ә Дәүләт Думасы вице - спикеры Сергей Бабуринның әнисенеке - Кульбедин.

**Примаков Евгений Максимовичның** (РФ Хөкүмәте башлыгы) фамилиясе XV - XVI гасырлардан килә. Киев Русендә яллы крәстиәннәр "приймаклар" дип, соңрак "батраклар" дип аталганнар. Евгений Максимовичның бабаларын Русьта "примак улы", ягъни батрак улы дип йөрткәннәр.

**Скуратов Юрий Ильич** (РФ Генераль прокуроры). Бу фамилия беренче тапкыр XV - XVII йөзләрдә телгә алына. Аның тарихы татар - монголларга барып тоташа. Ләкин мәгънәсе ягыннан бу фамилиянең төркиләргә катнашы юк. Явыз Иванның опричнигы Малюта Скуратов аның бик ерак бабасы булуы ихтимал.

**("Мәдәни җомга"дан алынды).**

## Коллектив һәм җитәкче

***Тәнзил Кәбирович үзенең нефтьчелеккә эшкә килүен бик табигый хәл итеп саный. Гомумән, бу беркемдә дә гаҗәпләнү тудырмый. 40 елдан артык гомерен кара алтын эзләүгә биргән Атказанган нефтьче, Хезмәт Кызыл байрагы ордены кавалеры бораулаучы Кәбир Гарәфетдинович Мусинның уллары да һөнәр сайлауда икеләнеп торсалар, кем әйтмешли, гөнаһ булыр иде! Татарстан нефтьчеләренең күчмә тормышын татып үскән Тәнзил гомере буе әтисенең үз һөнәре белән горурланып яшәвен яхшы хәтерли. Әтисеннән күп нәрсәгә өйрәнде ул. Мәрхүм Кәбир ага нефтьче өчен кирәкле өч сыйфатны еш кабатлый иде: түземлелек, исәнлек һәм кешеләрне аңлау. Кырыс һөнәр ияләре өчен соңгысы беренче икесеннән дә мөһимрәк булуын Тәнзил Кәбирович шул мохитта эшли башлауга төшенде. Һәм бүген шикләнмичә әйтергә була: Тәнзил Кәбировичның хөрмәтле җитәкче, мәгънәле шәхес булып җитешүендә нәкъ менә шушы сыйфат төп рольне уйнады да.***

# МУСИН УЛЫ БУЛСЫН ДА...

Нигездә ир - атлар эшләгән оешма җитәкчесендә чор дефицитына әверелеп барган кешелеклелек, игелеклелек сыйфатларының гүзәл тупланышына юлыгу безне шатлыклы гаҗәпләндерде. Соңрак тагы ачыш ясадык: ул сыйфатлар әле аңарда шулкадәр мул икән, алар, Тәнзил Кәбирович җитәкчелек иткән оешмага да "йогарга", аны җылы атмосфералы, сизгер күңелле нык максатлы коллектив итеп берләштерергә өлгергән.

"Лениногорск тампонаж эшләре идарәсе" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьнең Нурлат филиалы елъязмасы 1997 елның 1 февраленнән генә башлангыч алса да, ул буш җирдә түгел - "ТН - Нурлатнефтеразведка" АҖнең тампонаж цехы нигезендә оештырыла һәм Т.К.Мусин ул чорга коллективны 16 ел җитәкләргә өлгергән була инде. Бу вазифага кадәр Мусин Лениногорск нефть техникумын тәмамлый, тампонаж цехына урнашып, цементлау агрегаты машинисты, скважиналарны ныгыту буенча өлкән инженер булып эшли, һөнәри белем туплау белән бергә оештыру, кешеләр белән эшләү күнекмәләрен дә үзләштерә. Хәер, соңгысы аның өчен беркайчан проблема тудырмый. Иплелеген, гадилеген һәм гаделлеген тоеп, кешеләр үзләре аңа тартылалар, киңәшкә киләләр. Филиал оешкач та начальник вазифасына кандидатура бер була: Т.К.Мусин.



Филиал булып аерылып чыгу тампонажчыларга нәрсә бирә соң? Иң әүвәл, аларны бер предприятие мәнфәгатенә генә бәйлелектән азат итеп мөстәкыйльлек бирә. Үз - үзләрен табарга, расларга җай чыга. Хәзер, бораулау күләме тирбәлеп торган бер чорда, тампонажчылар да үзләрен шул дулкын колы итеп тоярга мәҗбүр булырлар иде. Ә мөстәкыйль тампонажчылар үз көчләренә таянып, канат җәеп эшли башлыйлар, хезмәт күрсәтү сферасы киңәя. Заказчылар арасында "ТН - Нурлатнефтеразведка" АҖ, НГДУ гына түгел, "Татнефтепром"ның Зүзәй НГДУсы һәм яшь, әмма нык аркалы "РИТЭКнефть" НГДУсы да бар. Соңгысы белән элемтәләре көннән - көн ныгый бара, заказчылар соравы буенча аларга транспорт хезмәте дә күрсәтә башладылар. Эшне шулай икътисадый файдалы итеп оештыруны Лениногорскида хуплыйлар гына, Нурлат филиалы җәмгыятьнең иң алдынгы, сәләтле берләшмәсе буларак танылу ала, ә җитәкченең эш стиле үрнәк итеп телгә алына башлый.

Филиалның төп хезмәт эчтәлеге шул ук кала: скважиналарны ныгыту - цементлау, юу сыекчаларын кудыру, скважиналарны опрессовкалау һәм юдыру. Төп һөнәр ияләре - цементлау агрегатлары мотористлары, цемент катнашмалары ясау агрегаты машинистлары, шоферлар... Инженер - техник хезмәткәрләр 5әү исәпләнә. 65 кешене берләштергән коллективның нигезен биредә кимендә 15 - 20шәр ел эшләгән һәм- иң мөһиме!- элекке нефтьчеләр уллары тәшкил итәләр. Тәнзил Кәбирович бу фактора тикмәгә генә басым ясамый - дәвамлылык җаваплылык һәр эшкә мөнәсәбәттә зур роль уйный. Бертуган Николай һәм Александр Токмаковлар, Евгений һәм Владимир Стрельниковлар, Александр Круглов, Константин Кудряшов - шундыйлардан. Начальник аларның нефть эшенә бирелгәнлекләрен югары бәяли. Шул ук вакытта мотористлар А.А.Смирнов, В.А.Жуков, С.Г. Булыгин, машинист В.А.Шабров, цемент ташу машинасы шоферы В.А.Алексеев, автобус шоферы В.П.Сидимировның да коллективта күптән үз урыннарын алуын сөенеп билгеләли. Гомумән, коллектив турында фикере гаять югары аның, һәркем турында озаклап сокланып сөйли ала. "Нуретдиныч мы?( Әйдәп баручы инженер Роберт Зәйнуллинны үз итеп шулай атарга яраталар). Ул бик көчле технолог, 30 ел инде безнең системада эшли. Заказчы белән мөнәсәбәт аның җаваплылыгында саклана. Эшне сыйфатлы, үз вакытында башкару турында иң әүвәл ул кайгырта".

"Инженер - механик Минәхмәт Вәлимөхәммәтович Кәбиров карамагында 34 техника, әле аның күбесе - махсус, өске җиһазлар белән. Гаҗәеп белемле, тәртипле механик ул".

"Скважиналарны ныгыту буенча инженер Әсгать Сөләйманович Закировның биредә эшләвенә әле ике генә ел була. Әмма зур хезмәт стажы белән килде, җаваплылыгына теләсә кем сокланырлык".

Ә тампонажчылар - хәтта Лениногорскида да! - Тәнзил Кәбирович кул астында эшләүне зур язмыш елмаюы итеп бәялиләр.

- Эштә төрле хәлләр була, хезмәтебез бит сәгатьле - нормалы гына түгел, әмма бездә беркайчан урынсыз тавыш күтәрү, шәхесне кимсетү дигән нәрсә юк. Нинди очракта да без Тәнзил Кәбировичның ышанычын югалтмаска тырышабыз,- диләр алар.

Бусын Мусин бик авыр кичерә икән.

Җитәкче һәр эшчесенең нәрсәгә сәләтле булуыннан гына түгел, тормыш - көнкүреш проблемаларыннан да әйбәт хәбәрдар, кулыннан килгәнчә аларны хәл итүдә булышырга тырыша. Уйлагыз әле: кайсы оешма начальнигы үз эшчесе авырып ятканда шифаханәгә хәл белергә бара? Тәнзил Кәбирович, һәм күп очракта икенче көнне үк!

Тампонажчылар җитәкчеләренең кунакчыллыгы, аш - су әзерләргә осталыгы, ипле - акыллы гаилә башлыгы булуы турында да сокланып сөйләделәр. Кәнәфи колы, түрә булуны җене сөйми икән. Югары һөнәрмәнлеге белән дә масаймый, киресенчә, бик теләп яңа белгечләргә булыша һәм производство мәсьәләләрен хәл иткәндә аның белеме һәрчак иң отышлы карарга килергә ярдәм итә. Һәр тармактагы кебек, биредә дә яңа прогрессив алымнар кереп тора, камилләштерү бара бит. Әле менә цементлауда "осреднительная емкость"- аралаштыру сыешлыгы куллана башлаганнар, бу цементлау технологиясен бермә - бер яхшырта. Тәнзил Кәбирович андый очракларда һәрчак яңалык ягында, тизрәк аны производствога кертү хәстәрендә. Филиалның план үтәми калган чагы да юк: быелның 10 аенда алар тампонаж эшләре планын 113 процентка башкарып чыгалар, бу - җәмгыятьтә иң югары күрсәткечләрдән. Ул заказчылар белән эшлекле, акыллы хезмәттәшлекне саклый һәм коллективны да шул максатка туплый. Чөнки белә: нефть эшендә вак - төяк нәрсә юк, ул барьяктан намуслы һәм гадел хезмәт куюны сорый. Аның әтисе кебек. Яки үзе кебек, чөнки шушы көннәрдә генә "Лениногорск тампонаж эшләре идарәсе" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьнең Нурлат филиалы башлыгы Тәнзил Кәбирович Мусинга ТР Президенты Указы белән "Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе" дигән мактаулы исем бирелде. Тәнзил Кәбирович моны әтисе ядкаренә һәм һәр икесе гомерен багышлаган хезмәткә тугрылыгын бәяләү дип кабул итә. Ә кешелеклелеге, гаделлеге өчен иң югары бәягә ул күптән ирешкән инде: ул - хезмәттәшләренең тирән хөрмәте, эчкерсез мәхәббәте.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: Т.К.Мусин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

---

Бер семинар уңаеннан

# «КОНКУРСТА КАТНАШУДАН КУРЫКМАГЫЗ!»

***Россия Дәүләт Думасы, РФның Мәгариф Министрлыгы һәм "Педагогический вестник" газетасы мәктәпкәчә һәм мәктәп учреждениеләре арасында Бөтенроссия конкурсы игълан иткән иде. Шул бәйгедә безнең районнан җиде учреждение - "Кояшкай", "Светлячок", "Чишмәкәй", Иске Чаллы балалар бакчалары мөдирләре һәм Кече Камышлы, Абрыскино, Сәләнгеш мәктәпләре директорлары лауреат исеменә лаек булып семинар - киңәшмәгә чакырылдылар. Лауреатларның берсе бнчы "Кояшкай" укыту - тәрбия комплексы мөдире Суфия Шәфыйковна СӨЛӘЙМАНОВА Мәскәүгә семинар - киңәшмәгә барырга мөмкинлек таба һәм бүген ул укучыларга, коллегаларына аннан алган тәэсирләрен җиткерә.***

Мәскәү... Бүген аңа карата сүзләрнең, фикерләрнең төрләре - уңайлары һәм тискәреләре дә булуга карамастан, ихластан әйткәндә, балачактан ук Мәскәүгә - илебезнең йөрәгенә карата булган җылы хисләр күңелнең бер читендә саклана әле. Мәскәүгә Бөтенроссия конкурсында җиңеп чыккан балалар бакчалары мөдирләре белән иҗади очрашу, киләчәктә эшебез, яшәешебез турында фикер алышуга мин шулай ашкынып бардым. Безне, Россиянең барлык регионнарыннан килгән 300дән артык лауреатны искиткеч җылы каршылады ул. Семинарны оештыру комитеты рәисе "Педагогический вестник" газетасының учредителе Л.И.Рувинский алып барды. Анда академиклар, профессорлар чыгыш ясады. Аеруча, минем карашка, атаклы академик Н.Н. Поддьяковның чыгышы уңышлы булды.

Хәзерге болгавыр заманда ничек эшләргә? Ничек итеп балалар бакчаларын саклап калырга? Нинди программаларга таянырга, аларны ничек гамәлгә ашырырга? Бу җәһәттән "Чишмәләр", "Балачак", "Салават күпере" тибындагы программалар әйбәт дип табылдылар. Әмма эшне нинди генә программа нигезендә корма, балаларның физиологик һәм психологик яктан иминлеген кайгырту, балага шәхес итеп карау, тәрбиячене программа буенча эшләргә өйрәтү бакчада төп юнәлешне алып торырга тиешләр.

Балалар бакчасы бала өчен бәхет, шатлык урыны булырга тиеш - менә ничек куела хәзер мәсьәлә. Бала күбрәк көләргә, уңай эмоцияләр белән яшәргә тиеш. Моның өчен, әлбәттә, тәрбиячёнең эшне юморга нигезләнеп коруы мөһим. Ә программа бу җәһәттән ориентир булып тора.

Семинарда мәктәпкәчә яшьтәге балаларны ирексезләп укырга, язарга өйрәтү кискен тәнкыйть утына тотылды. Безнең төп бәлабыз да шунда: баланың физик һәм акыл ягыннан үсеше акрын баручы процесс икәнлекне онытып, аңардан тизрәк "талант иясе" әвәләргә тырышабыз. Балалар бакчасын белем бирү учреждениесенә әйләндерергә ярамый, диделәр семинарда бертавыштан. Ә менә белемгә омтылышны төрле яклап тәрбияләү, әхлак нормаларын өйрәтү - алары балалар бакчасы өчен иң мөһим максатлар. Сер түгел, укый - яза белүче баланың исәнләшә яки рәхмәт әйтә белми торган чаклары да була бит.

Йомгаклау сүзендә оештыру комитеты рәисе безне "Педагогический вестник" газетасы белән элемтәне өзмичә эшләргә чакырды. Ул - балалар бакчасы, мәктәп тормышын киң диапазонда чагылдыручы, яңалыклар алып килүче бердәнбер газета, ул - чын мәгънәсендә педагоглар трибуны дияр идем мин.

Семинар барышында өч көн буена бай методик әсбаплар күргәзмәсе эшләде. Өстәвенә, җиңүчеләргә бүләк итеп, күп кенә матур әдәбият та бирелде.

Семинарда катнашуымнан мин зур горурлык хисе кичердем, республика, районыбыз өчен куандым - без, татарстанлылар семинарда катнашучы иң зур төркем булдык. Кечкенә генә Нурлат шәһәреннән ил күләмендәге семинарга чыгуда ярдәм итүче район мәгариф бүлегенә чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә.

Коллегаларыма шуны җиткерер идем: конкурсларда катнашудан шүрләп калмагыз, иҗади эшләргә, һәрвакыт эзләнергә тырышыгыз. Конкурслар, семинарлар җанга ял бирә, күзаллауны киңәйтә, аң - белемне арттыра, аннары яңа дуслар, танышларның артуы да безнең һөнәр кешеләре өчен аз нәрсә түгел. Сезгә игелекле эшегездә яңа үрләр яулавыгызны теләп калам.

# БЕРГӘ БАРЫБЕР ҖИҢЕЛРӘК...



"Ак таяк" көннәре үткәрү Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте районара оешмасы тормышында традициягә керде. Нурлатта андый чара быел көз ахырында - ноябрьдә уздырылды. Аның нәкъ менә еллык эшкә йомгак ясар чакта үтүендә символик мәгънә дә бар. Быелгы очрашу дәүләт, хуҗалык органнары, җәмәгатьчелек һәм матбугатның күрмәүчеләр проблемаларына игътибарын юнәлтүне максат итеп куйган иде. Ни генә әйтсәң дә, гадәти кешеләрнең дә проблемалары җитәрлек хәзер, ә аеруча яклауга мохтаҗ катлау - күрмәүчеләрдә ул проблемалар тагын да күп.

Ә күрмәүчеләрнең мәшәкатьләре бик гади. Озак вакытлар районда пенсия һәм пособиеләр тоткарлыксыз бирелеп килсә дә, хәзерге икътисадый сәбәпләр аркасында ул мәсьәләдә дә кыенлыклар килеп туды, һәм бу ВОСчыларның проблемаларын көн туса ишәйтә. I группа инвалид А.Ниценко, мәсәлән, тере акча күргән юк, азык - төлек чекларына гына яшибез, ә бит институтта укучы улыма да булышырга кирәк, тик ничек, ди. Куллану карточкасы буенча азык - төлек алырга, коммуналь хезмәтләр һәм телефон өчен түләргә мөмкин булса да, күрмәүчеләр өчен чыгарыла торган басмаларга язылып булмый. Аннары көнкүрештә кирәкле күп кенә товарларның бәясе дә күзгә күренеп күтәрелә. Алга таба хәл яхшырыр микән соң?

Очрашуда халыкны социаль яклау идарәсе белгече М.Хөсәеновага гына түгел, АТПның эксплуатация начальнигы Т.Ибраһимовка да күрмәүчеләрнең күп кенә үтенечләрен тыңларга туры килде. А.Маркин, В.Иванов һәм башкалар автобус шоферларының ни өчен кайчагында туктальшларда күрмәүчеләрне калдырып китүләре белән кызыксындылар. Шәһәрара рейсларда льготаларның кайсы вакытларда гамәлдә булуы да кызыксындыра сукырларны, контролерларның елгырлыгы да борчый: күрмәүчеләрне физик яктан сәламәт кешеләр белән бер рәткә куярга кирәкми, тукталышта кулындагы ак таягын күтәргән кеше басып тора икән, шофер, машинаңны туктатып аңа юл аркылы чыгарга мөмкинлек бир син - бозлавыкта сәламәт кешегә дә атлавы кыен бит.

Шулай да күрмәүчеләрнең иң күп сораулары ЮХИДИ начальнигы Х.В.Әюповка булгандыр. Шунысын әйтергә кирәк, җыелганнарның власть әһелләренә карата мөнәсәбәте яхшы ниятле рухта иде: алар үпкә белдерү максатыннан түгел, ә хәлнең ниндилеген аз булса да аңлау, проблемаларын, әле алары да шәхсидән бигрәк күмәк, бераз гына булса да җиңеләйтү теләге белән сүз кузгаттылар. Мисал өчен, мәктәп балаларының Завод урамында, шулай ук НГДУның административ бинасы янындагы юл чатында курыкмыйча исән - имин йөрүен ничек тәэмин итәргә? Күп айлар инде шәһәрдә светофорлар эшләми һәм бу җәяүлеләргә дә зур куркыныч тудыра. Кием - салым базары янында автомобильләр куяр өчен урын кайчан булыр икән? - барлык бу сораулар да ЮХИДИ начальнигы ясаган информациядә чагылыш тапты. Зур кызыксынучанлык белән узган бу әңгәмәдә күрмәүче инвалидлар Г.Идрисова, В.Осипова һәм башкалар актив булдылар. Очрашуда хакимият вәкиле - җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч Р.Сингатуллина да катнашты. Шәһәр һәм район хакимияте сукырлар оешмасы эшчәнлегенең социаль әһәмиятен, күрмәүчеләрнең проблемаларын яхшы аңлый, аларның мөрәҗәгатьләренә колак сала. ВОС оешмасы рәисе З.Богданова чыгышында да чагылыш тапты анысы. Районда күрмәүчеләргә йортларын төзәттерү һәм газлаштыруда ярдәм күрсәтелә, кирәк чакта транспорт бирелә, чараларның да бер өлеше финанслана. Менә бу матбугатка язылу кампаниясе чорында да күрмәүчеләрнең "Безнең тормыш" дигән журналларына язылуга да район бюджетыннан акча бүленде.

Гомумән алганда, "Ак таяк" көне күрмәүчеләрнең проблемаларына җирле властьларның да, җәмәгатьчелекнең дә битараф түгеллеген күрсәтте. Ә бу алар өчен һәрчак мөһим булды. Бу катлаулы чорда бигрәк тә.

**Т.НАЗАРОВА.**

---

## Аш - су



***Тиздән авылларда каз өмәләре башланачак. Татар халкы элек - электән каз үстерә белә ул. Аны ничек пешерү, каклау турында да киңәш сорап күршегә керми. Шулай да, каз каклау турында безнең киңәшләргә колак салсагыз да зыян итмәс.***

## КАКЛАГАН КАЗ

**Беренче ысул.** Казның өслеген тоз белән уып, муен, эч куышлыгына тоз белән бодай ярмасын (0,5 кг тоз, 1 кг бодай ярмасы) бутап тутыралар. Аны башта йомшак кәгазьгә төрәләр, аннан иске, чиста итеп юылган чүпрәк белән урап, өстеннән тузган эластик оек кигертәләр. Оекның икенче башын тартып, аркылыга уратып бәйләп куялар. Казны суйган көнне үк тозласаң, аны теләсә нинди урында сакларга була.

**Икенче ысул.** Чистартып юган бөтен казның эченә - тышына яхшылап тоз сөртеп, пергамент яисә целлофанга һава кермәслек итеп төрергә дә, бау белән бәйләп он эченә тыгарга яки җилсез караңгы урынга элеп куярга кирәк. 3 - 4 айдан каз какланып җитә, ите кызгылт төстә, тыгыз була, бармак белән баскач, мае сыгылып чыга. Каклаган казны салкынча урында 2 - 3 ел сакларга мөмкин. Озак торган саен тәмлерәк кенә була. Каклаган казны пешереп тә,чи килеш тә ашыйлар.

## ТӨТЕНДӘ ЫСЛАНГАН КАЗ

Чистартып юылган казның эченә - тышына тоз сөртеп яки тозлы суга салып бер тәүлек тоталар. Судан алгач казны корытып сөртәләр,ботын, канатларын түшкәсенә кысып бәйлиләр, аннары ике бүлешле махсус тимер мичтә ыслыйлар. Казны мичнең уртадагы алынмалы рәшәткәсенә куялар да аскы өлешенә ут ягалар. Ыслау өчен вак итеп ярган имән, каен, усак утыны яки шуларның пычкы чүбе кирәк. Гадәттә 10 - 12 сәгать ыслыйлар. Казны өйдәге мичтә дә (төтен юлында) ысларга мөмкин.

Бүлмә температурасында суыткач, ысланган казны коры чүпрәк белән сөртеп, урталай бүләләр, аннары ике бармак киңлегендә аркылыга турыйлар.

**("Заман - Татарстан" нан).**

---

## *01 хәбәр итә*

## УТ ҮЗЕННӘН - ҮЗЕ ЧЫКМЫЙ

14 ноябрьдә Нурлатның Южная урамындагы 9нчы йортта И.Фәйзуллина хуҗалыгында янгын чыкты. Сәбәбе электр үткәргечендәге кыска ялганыш була. Хуҗа хатын тавыклар абзарындагы утны кабызып калдыра. Анысы кыш җитсә гадәти хәл - күпләр тавыкларына яктырак һәм җылырак булсын дип сарайларында электр уты кабызып калдыралар. Ә күп кенә хуҗалыкларда электр үткәргечләр кагыйдәне бозып сузылган була, электр лампочкаларының плафоннары юк, электр үткәргечләрнең очлары изоляцияләнмәгән чаклар да еш.

18 ноябрьдә Гыйматдинов урамындагы 15нче йортта Р.Рахманкулов хуҗалыгында мунча янды. Сәбәбе - мичнең кызуы.

## УРАМНАРДА КАРАҢГЫ

Кадерле редакция! Сезгә балалары тимер юлчылар поселогындагы 8 нче мәктәптә укучы ата - аналар мөрәҗәгать итә. Эш менә нәрсәдә. 5-6 класс балалары төштән соң укыйлар. Дәресләр кичке сәгать биштә, инде караңгы төшкәч бетә. Ә Калинин урамында, мәктәп янында, Красноармейская урамы буйлап Молодежная урамына кадәр баганаларда ут юк - лампочкалар янып чыккан, күрәсең. Тик аларны алмаштырырга уйлаучы күренми. Менә шуңа да балаларыбыз өчен борчылабыз инде без -каршы алыр идек, әле ул чакта эштән кайтып җитмәгән булабыз. Безнең бистә урамнарында төрле кеше йөри, сукбай этләр дә җитәрлек. Җирле властьлар бу мәсьәләгә игътибар итсеннәр иде дибез.

**Бер төркем ата -аналар исеменнән Сергеева.**


## ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ

***НГДУның Нурлат технологик транспорт идарәсе конкурс нигезендә автоэлектриклар, ЦА - 320 машинисты, ППУ\АДП машинисты, телевышка машинисты, күтәрткеч агрегат машинистын эшкә чакыра. Кимендә 3 ел эш стажы булу шарт.***

НУРБ коммутаторы аша 65-5-12 телефоны буенча УТТның кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.


---


***БЕЛМИ КАЛМАГЫЗ, КИЛМИ КАЛМАГЫЗ!***

## ВИТАЛИЙ АГАПОВ - НУРЛАТ СӘХНӘСЕНДӘ.




***Тамашачылар соравы буенча 1 декабрьдә район мәдәният йортында танылган көйләр остасы һәм башкаручы Виталий Агапов һәм аның концерт төркеменең зур чыгышы була. Концертка рәхим итегез!***

***Башлана кичке сәг. 7дә. Билет хакы 20 сум.***


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА


### САТАБЫЗ

**"Славутич" төсле телевизоры.**
Адрес: Циолковский ур., 7 - 37, кичке 6дан соң.

***

**Яңа кул тегү машинасы.** Тел.: 2-19-87.

***

**ВАЗ - 2103, кыйммәт түгел.**
Адрес: Тельман ур., 30 - 4.

***

**Төргәктә электр тегү машинасы (Япония).**
Тел.: 5-12-72.

***

**Телевизор (257 сум) һәм баян, кыйммәт түгел.**
Адрес: Горький ур., 23.

***

**26 ноябрьдә универмагның беренче катында, шулай ук шимбә һәм якшәмбе көнне кием - салым базарының икенче залы янында Ульяновскида чыгарылган аяк киемнәрен сату була.**

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Ике бүлмәле фатирны - өстәмә түләп бер бүлмәлегә.** Адрес: Завод ур., 5 - 15.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Зөлфәт Миннегәрәй улы Шәвәлиев исеменә шофер таныклыгы табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Тел.: 2-14-28.

***

**Авторезина шиплыйм.**
Адрес: Ленинград ур., 9 - 2. 5 сер. № 673 таныклык.

***Чикләнгән җаваплылыктагы "Агростройсервис" җәмгыяте пенсионерларның җиңел машиналарын пенсия хисабына ремонтлау хезмәте күрсәтелүе турында хәбәр итә.***
Безнең адрес: Завод ур., 1. Б -97 № 024312 лицензия.

**Авторезиналар шиплау. Шипланган теләсә нинди авторезина. Китереп бирәбез. Б - 97 № 288882 лицензия.** Тел.: 5-35-91, 2-35-59.

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 27нче ноябрь һәм 11нче декабрьдә көндезге сәгать 12дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


"Кондырча" авыл хуҗалыгы кооперативы коллективы алдынгы механизатор **Әсхать Вазыйх улы Тәмаевның** вакытсыз вафат булуын тирән кайгы белән белдерә һәм мәрхүмнең туганнарының, якыннарының авыр хәсрәтен уртаклаша.

Чулпан участок сырхауханәсе коллективы **әтисе Нәгыйм Минһаҗетдин улы Минһаҗетдиновның** вафат булуы сәбәпле Надия Нәгыйм кызы Төхфәтуллинаның авыр хәсрәтен уртаклаша.


МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4561